**СОВЕТ**
**Иж-Бобьинского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Иж-Бубый авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2021 Иж-Бубый авылы № 13-3

Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан генераль планнарны, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау, эшләү һәм әзерләү, генераль планнар нигезендә территорияне планлаштыру документларын раслау буенча Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, "Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының генераль планнарны, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, җирле нормативларны раслау, территорияне планлаштыру буенча генераль планнар нигезендә әзерләнгән документларны раслау, эшләү һәм әзерләү вәкаләтләрен Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына гамәлгә ашыруны тапшыру турында" Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2021 елның 15 декабрендәге 13-3 номерлы карарын исәпкә алып, Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге **КАРАР ИТТЕ**:

1. Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына генераль планнарны, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау, эшләү һәм әзерләү, генераль планнар нигезендә территорияне планлаштыру документларын раслау буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итәргә.

2. Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән генераль планнарны, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау, эшләү һәм әзерләү, генераль планнар нигезендә территорияне планлаштыру документларын раслау

буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча кабул итү-тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән Килешү рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының портал составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында элеп халыкка чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Р. ВАҺАПОВ